УДК 82

***Ситдыйкова Ч.Ф. , филология фәннәре кандидаты***

***«Language+» студиясе***

***Мәкалә «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4. санлы чарасы чикләрендә башкарылды.***

# Н.ГЫЙМАТДИНОВАНЫҢ 1970-1985 ЕЛЛАР ПРОЗАСЫНДА ПОЭТИК АЛЫМНАР

*Аннотация: Мәкаләдә Н.Гыйматдинованың 1970-1985 еллар прозасында кулланылган поэтик алымнар, психологизм чаралары өйрәнелде, әсәрләрдә контраст образлар, символик детальләр, табигать һ.б. бирелеше анализланды.*

*Төп төшенчәләр: проза, психологизм, алым.*

***Sitdikova Ch.F., Candidate of Philological Sciences***

***Studio «Language+»***

# POETIC TECHNIQUES IN N.GIMATDINOVA' S PROSE OF 1970-1985'S

*Abstract: The article is devoted to poetic techniques, psychologism in N.Gimatdinova's prose of 1985-2020's. Contrasting images, nature, symbolic details ect. are analyzed in this work.*

*Keywords: prose, psychologism, technique.*

Н. Гыйматдинова әдәбиятка 1970 еллар башында килә, беренче хикәяләре «Азат хатын» журналында басылып чыга, 1981-1986 елларда «Су хикәяте» (1981), «Бердәнберем» (1983) һәм «Талпыну» (1986) исемле җыентыклары дөнья күрә. Әлеге тупланмалардагы хикәяләрдә автобиографик мотивлар өстенлек итә: совет чоры кешеләре, бигрәк тә яшьләр, аларның тормышы, дөньяга карашы, характерлары формалашуы, хис-кичерешләре тасвирлана. Язучы үзенә таныш, якын вакыйгалар, хәлләр

турында яза, шәхси тормыш тәҗрибәсе белән бәйле рәвештә шул чор өчен мөһим булган мәсьәләләрне күтәрә. Күпвакыт әсәрләрдә, мәхәббәт яисә җавапсыз мәхәббәт темасына бәйле, романтик башлангыч алга чыга. Бер үк вакытта әсәрләрдә схематизм, характерларның тормыш шартларына тәңгәл килеп бетмәве кебек сыйфатлар да күзәтелә.

«Очрашу» (1981) хикәясенең үзәк герое буяучы кыз Марсилә − үз хезмәтен яратып башкаручы, яңа йортларны бизәп, үзен чиксез бәхетле тоючы кеше. Эшкә аны мәхәббәте рухландыра: Марсиләгә хезмәт сөяргә, үз хезмәтеннән канәгатьлек алырга өйрәткән Риф аның остазы гына түгел, сөйгән кешесенә дә әверелә. Ләкин кыз егеткә үз хисләрен белдерми. Риф укырга китә, берничә елдан җитәкче булып кайта, аның кыяфәтен язучы болай тасвирлый: «гади комбинизонны кара костюм, ак күлмәк алыштырган, хәтта чәчләре элеккечә тузып тормый, бер якка пөхтәләп тарап куелган» [3, б. 8]. Рифның холкы да үзгәреш кичергән, ул – чыныккан, көчле, кырыс. «Мин сине мондый пычрак эштә калырсың дип көтмәгән идем, Марсилә» [3, б. 8], дигән сүзләре кыз өчен мыскыллау булып яңгырый, ул аларны җитәкче кешенең гади эшчегә түбәнсетеп каравы кебек кабул итә. Асылда, бу сүзләр – Рифның Марсиләне алга барырга өндәве. Әсәрдә «апрель тамчылары» өмет, ышаныч символы буларак кулланылган.

Моңа охшаш ситуация Н. Гыйматдинованың «Яшь күңел» (1981) хикәясендә чагылыш таба. Романтик иҗатка хас булганча, мәхәббәт, саф хисләр тирәлекне, геройны үзгәртү чарасына әйләнә. Язучы төзелешкә мәҗбүри килгән кыз Назыйрәнең хис-кичерешләрен, остазына гашыйк булу күренешен сурәтли. Укытучы булырга хыялланган кыз өчен төзелештә эшләү шактый авыр була. Назыйрәне рухландыручы кеше − остазы Разил. Ахыр чиктә кызда буячы һөнәренә сүнмәс мәхәббәт уяна. Разил ярдәме белән кыз буяган стеналар «җырлап тора».

«Су хикәяте»ндә (1981) табигать халәте геройның кичерешләре белән тәңгәлләшә (суның шашып аккан чагы – герой күңелендә ташыган хисләр). Буячы кыз Рәфинә тормышындагы югалтулар да, табышлар да Су белән

бәйле. Ул сөйгән кешесен теплоходта очрата, давыл вакытында Айнан һәлак була, Гриша белән аларны янә Су таныштыра һәм аера. Бик авыр вакытларында хатын, ярдәм көткәндәй, Су янына омтыла. Герой халәтенә бәйле рәвештә су – «югалту», «тынычлану», «киләчәккә ышаныч» символы буларак бирелә.

Шул ук вакытта язучы әсәрдә совет системасына тәнкыйди карашын белдерә; сәяси хаталарны барлау, бәяләү, үкенү мотивы калкулана. Традицион производство әсәрләрендәге кебек, урындагы җитәкчеләрнең намуссызлыгы стажер егет Илдус образына бәйле яктыртыла. Янып-көеп эшләүче Рәфинәгә төзелеш прорабы Кадыйров кушуы буенча зыян китерүе Илдусны вөҗдан газабына сала. Ахыр чиктә ул, Рәфинәдән гафу үтенеп, хокук органнарына мөрәҗәгать итә. Кадыйров үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртучы, әхлаксыз герой булып күз алдына баса. Совет хакимияте «төзегән стенаның төртке-төртке булып кубып төшү» детале – совет чорының ясалма асылына, ялган идеалларына, ахыр көннәре җитүгә ишарәли. Әмма язучы каләменә мондый катлаулы мәсьәләне күтәрерлек тәҗрибә җитмәү дә үзен сиздерә.

Иҗади үсешнең бер юлын язучы каршылыкларны төп әйдәп баручы көчкә әйләндерүдә күрә. «Җан тынычлыгы» (1981) хикәясендә гадәти авыл гаиләсе тормышы мисалында әхлаклылык проблемасы күтәрелә. Хисмәт авыл халкыннан үз хезмәте өчен акча алмый. Шушы факт әсәрдә каршылык тудыра: комсыз хатыны тарафыннан «акча эшләмисең, акча юк» дип битәрләнгән ир яшәргә каравыл йортына күчә, биредә җан тынычлыгы таба. Хикәянең исеменә чыккан «җан тынычлыгы» язучы йөз тоткан романтик иҗат концепциясен күрергә ярдәм итә.

Әсмабикәнең «игезәге» − «Көмеш тәңкә» (1981) хикәясендәге бухгалтер Закир, ул язучы кире кага торган тормыш моделенең билгесенә әйләнә. Гомерлек тормыш юлдашын да «ведомость ярдәмендә» сайлаган ир көмеш тәңкә өчен бер түтәл гүзәл чәчәкләрне юкка чыгара. Шушы кечкенә бер күренеш-деталь Закирның комсыз, вакчыл адәм булуын дәлилли.

Әсәрләрдә авыл кешеләренең тормышы гадәти, көндәлек ыгы-зыгысында, хезмәткә һәм көнкүреш мәсьәләренә бәйле сурәтләнә. Шушы фонда характерлар каршылыгы ачыла. Әйтик, «Торна кияве» (1983) әсәрендә язучы хезмәт сөюче, тырыш сыер савучы хатын Гайфәрә һәм «кәкре каенлы йортта ярым-йорты тормыш алып баручы Торна Гарәфие» [3, б. 20] образларын күз алдына бастыра. Ике герой кушылып уртак тормыш кора алмый, чөнки аларның максатлары, холыклары бер түгел. «Китек Сәгыйрь» (1983) хикәясенең үзәгенә авыр авыл тормышыннан, эштән качып шәһәргә киткән кешенең күңел газаплары куела, аның асылын сагыш, үкенү «камап алган». Язучы туган җиренә битараф кешеләрнең бер урында да бәхетле була алмавын ассызыклый.

Артистлар, рәссамнар, журналистлар тормышы, аларның үз эшләренә мөнәсәбәтләре, яшәү максатлары һәм принциплары мәсьәләләренә кагылган хикәя-повестьлар Н. Гыйматдинованың башлангыч чор иҗатында аерым урын алып тора. Гомумән, алтмышынчы – сиксәненче еллар әдәбиятында интеллигенция вәкилләренә игътибар арта. Әлеге елларда иҗат ителгән А.Расихның «Ике буйдак» (1965), Г.Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» (1965), А.Гыйләҗевның «Урамнар артында яшел болын» (1968), М.Мәһдиевның «Без – кырык беренче ел балалары» (1968), «Фронтовиклар» (1972), М.Маликованың «Шәфкать» (1983), Э.Касыймовның «Бир кулыңны, дустым» (1969) һ.б. әсәрләр шул хакта сөйли. Әлеге әсәрләрдә төп конфликтлар гражданлык һәм мещанлык, халык тормышына һәм эшенә шәхси җаваплы караш белән бары үз мәнфәгатьләрең турында гына кайгырту арасында хасил булалар. Авторлар, үз чорының идеологик карашлары рухында фикер йөртеп, югары гражданлык сыйфатларына ия булган замандашның, аның актив тормыш позициясенең мещанлык фәлсәфәсеннән, яшәү рәвешеннән өстен чыгуын күрсәтәләр. Бу герой еш кына социалистик яшәү рәвешен үзендә чагылдырган, аның тормышта тантана итүе өчен көрәшкән шәхес итеп алга бастырыла [5, б. 25]. Н.Гыйматдинованың «Күңел күзе» (1983), «Ата белән бала» (1983), «Талпыну» (1986) әсәрләрендә

зыялылар тормышы төрле каршылыкларга (героиняның үз эчендәге каршылыгы, тирә-юньдәгеләр белән каршылыгы һ.б.) бәйле рәвештә сурәтләнә, әхлакый нәтиҗәләргә алып килә.

Әйтик, «Ата белән бала» повестенда конфликтка китерүче төп сәбәп – гаиләгә үзенчәлекле караш. Бу – Гөлүсә-Идрис, Гөлүсә-Галләм ага, Гөлүсә-аның этисе мөнәсәбәтләрендә чагылыш таба. Идрис − гаиләгә, хатынына, балаларга битараф кеше, эгоист. Гөлүсә исә, гаилә өчен яши. Идриснең бала төшерергә кушуы героиняның эчендә каршылык барлыкка китерә – ул икеләнә, нишләргә белми (аерым бер вакытта ире әйткәннәрне үтәргә дә әзер). Әсәрдә Идрис образының игезәге дә бар: ул – «җырны − үлем», «артистларны − урам этенең сыңары» дип санаган кырым кешесе, Гөлүсәнең чын этисе. Язучы аның исемен дә атамый, төс-кыяфәтен дә тәфсилләп тасвирламый, бары теге яки бу ситуациядә башкарган эш-гамәлләрен генә күрсәтә. Әсәр ахырында инде бу затның эгоист кына түгел, шул эгоистлыгы аркасында бәхетсез кеше булуына инанасың. Аның капма-каршысы Галләм ага − миһербанлы, сабыр кеше, Гөлүсәне үз кызы кебек ярата, дөрес юлны сайларга булыша. Гөлүсә-Галләм образлары ярдәмендә «ата белән бала» мөнәсәбәтләренең матур үрнәге ачыла.

Язучының «Күңел күзе» повестендагы журналист кыз Марсилә – дөреслек, хаклык өчен көрәшүче герой. Марсилә көчсезләрне кызгана һәм аларга ярдәм итәргә һәрчак әзер. Кызның бу сыйфатына әсәр башында ук басым ясала: кыз яралы көчекне коткара. Алга таба Марсилә энергияле, талантлы, кыю, намуслы журналист буларак сыйфатлана. Прораб Алеша аны «намус судьясы» дип атый.

Әсәрдә каршылык Марсилә белән сөйгән кешесе Шамил арасында хасил була. Журналистлык эше − Марсиләнең яшәү максаты; Шамил исә, аның эшләвенә каршы. Язучы Шамилне үз-үзен генә яратучы, берникадәр куркак, битараф кеше буларак сурәтли. Автор ир белән хатын арасындагы каршылыкны тулы чагылдыру өчен хат алымына мөрәҗәгать итә. Шамилнең үз кичерешләрен, уйларын телдән белдерү өчен теләге дә, кыюлыгы да

җитми: «Сез – өй бизәге, бала үстерүче ана, сөекле ир хатыны итеп яратылган гүзәл затлар. Ташла журналистлыгыңны» [3, б. 85], дип язылган сүзләре Марсилә белән араларын тагын да ерагайта, мәсьәләне кискенләштерә.

«Талпыну» повестенда сәнгатьнең тормыштагы урыны-роленә язучы фәлсәфи якын килә, Мәрьям образы аша үзенең эстетик идеалын укучы күз алдына бастыра. Мәрьямне кечкенә вакытта әнисе ташлый. Ул тормышның ачысын-төчесен үз җилкәсендә татый: авыр физик хезмәт, авылдашларының кырын каравы һ.б. Язучы аның аерым сыйфатларын күпертеп куя: Мәрьям – гадел, дөреслеккә баручы, максатына ирешүчән, саф күңелле. Сөйгән яры Илгизәрнең әнисе Минбәдәрнең фермада сөткә су өстәвен күргәч, кыз хатынның ялганын фаш итә. Бу хәлдән соң Илгизәр аңа әнисен кешеләр алдында акларга куша, ләкин кыз алдау юлына басмый. «Син, Илгизәр, көнгә өч мәртәбә битеңне юарсың, кардай ап-ак күлмәк киярсең, ә күңелеңдәге мәкерне су белән дә юалмассың, ак күлмәк тә кигезә алмассың. Кеше тәне белән түгел, җаны белән карала» [4, б. 141], – дип җавап кайтара.

Н. Гыйматдинованың 1970-1986 елларда иҗат ителгән күпчелек әсәрләрендә ике катлы тормыш моделе төзелә, хыял-идеалдагы модельдә рухи башлангычның өстенлеге ассызыклана. Әмма чиктән тыш арттыру аша ике төрле яшәү рәвешен каршы кую кайчак әсәрләрнең ышандыру көчен киметә, бер үк вакытта укучыга тәэсир итү, мавыктыру мөмкинлеге бирә. Мәсәлән, романтик рухта язылган «Хыял» (1983) повестеның төп герое – тормыш-яшәешнең авырлыгына, гаделсезлегенә борчылучы романтик, рәссам Динә. Аның өчен камил булмаган тормыштан бердәнбер качу урыны – хыял дөньясы. Әсәрдә төп каршылык та романтиклардагыча: хыял һәм чынбарлык арасында. Сәнгать кешесе буларак, Динә талантлы, матурлыкны күрә белә, иҗаты аша тормышны «якты төсләргә» буярга омтыла. Чынбарлык исә, «караңгы төсләр»гә буялган. Төсләр символикасы әсәрдәге каршылыкны тагын да кискенләштерә. Геройның уйлары, кичерешләре, күңелендә барган үзгәреш-хәрәкәт алгы планга чыга. Ул геройдагы гомуми

канәгатьсезлек, дөреслеккә, идеаль тормышка омтылу кебек билгеләнә. Динә идеаль җәмгыять, бары якты төсләрдән генә торган тормыш турында хыяллана, андый урынның («планетаның») барлыгына ышана. Ялгышлар, каршылыклар аша герой хакыйкатьләр ача, нәтиҗәләр ясый. Язучының максаты − шушы юлдан баручының күңелендәге гамь-борчуларын, соклануларын, тирән кичерешләрен укучыга җиткерү кебек тоела. Динә образына, аның хис-кичерешләренә бәйле рәвештә ике төрле тормыш – күңегелгән җир тормышы һәм илаһи-идеаль дөнья үзәккә куела.Күнегелгән тормыш-чынбарлык тәнкыйтьләнә, пессимистик компонент ачык билгеләнә башлый. Хыял һәм чынбарлык арасындагы чикләр җуела. Хыялдагы тормышны идеаллаштыру, хыялга мөрәҗәгать итү, аның белән аралашу, фәлсәфи һәм лирик чигенешләр ясау күзәтелә. Рухи башлангычның өстенлеге ассызыклана. Герой үзенә чынбарлыкта табылмаган таяну ноктасын башка яссылыкта эзли башлый, үзенә күрә илаһи көч эзли һәм аны Хыял образында таба. Ул − Динәгә ярдәм, киңәш кирәк булган чакта пәйда булучы зат, бәлки сурәт. Динә аның белән аралаша, сөйләшә, киңәшләшә, килүен көтеп ала. Язучы матди һәм идеаль-хисси дөньяны аерып куя. Әсәрдә поэтик чаралар ярдәмендә сәнгатьнең тормыштагы урыны-роле билгеләнә: ул геройның яшәү рәвешенә әйләнгән. Гомумән, Н. Гыйматдинованың бу чор әсәрләренең структурасын идеаллаштырылган тормыш рәвешен пропагандалау, аның капма-каршысын кире кагу хасил итә.

«Китмә, улым!» (1981), «Бердәнберем» (1983) повестьларында сугыштан соңгы еллар тормышы геройның шәхси кичерешләре аша яктыртыла. «Китмә, улым!» әсәрендә төп герой Талипның бүгенгесе үткәне белән үрелеп бара (вакыт белән уйнау алымы). Сугыштан исән-сау кайткан Талип – гадел, намуслы кеше. Аның капма-каршысы – үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртучы авыл рәисе Шәрук. Талипка нәфрәт белән янган рәис егетнең йөргән кызы Галимәне көчли, хатынлыкка ала, кыйный, авырлы килеш кыш көннәрендә салкында тота, ахырда өеннән куып чыгара. Алар

арасындагы аерманы язучы явызлык һәм яхшылык арасындагы мәңгелек көрәш дәрәҗәсенә күтәрә.

«Бердәнберем» повестенда сүз матурлык хакында бара (герой тормышының матурлыгы, ана белән бала мөнәсәбәтләренең матурлыгы, эчке матурлык һ.б.) Повестьта сугыштан соңгы еллар авырлыгы төп герой Гайшәнең башына төшкән шәхси авырлыклар белән үрелеп китә. Гайшәнең, башка бик күп хатын-кызларның кебек үк, ире фронтта һәлак була. Егерме бер яшендә ул тол хатын-кызлар исемлегенә керә. Гайшә тормышын балалар укытуга багышлый. Сугыштан соңгы елларда, ач, ялангач балаларга ярдәм итү өчен, ул өен, киемнәрен – бар булганын кызганмый.

Гайшә-Гөлсирин образларына бәйле әсәрнең үзәгенә ана белән бала арасындагы мөнәсәбәтләрнең матурлыгы чыга. Гайшә, «азгын» тормыш алып баручы хатын Рәшидә үлгәч, аның бер яшьлек баласын тәрбиягә ала, аны укыта, үстерә. Бала өчен барысын корбан итә − кияүгә чыкмый, урманда утын кисә һ.б. Ана белән бала арасындагы мөнәсәбәтләр аерым бер җылылык белән тасвирлана.

Эчке дөнья матурлыгы шофёр егет Марат образына бәйле күрсәтелә. Геройның портреты, тышкы кыяфәте аның эш-гамәлләре, үз-үзен тотышы белән ярашмый. Марат һәрчак Гөлсирингә ярдәм итә, аның яклаучысы була. Тышкы кыяфәт ямьсезлегенә, Ә. Еникинең «Матурлык» хикәясендәгечә, контраст рәвештә күңел дөньясының матурлыгы каршы куела. «Ямьсез егет... Ямьсезмени ул? Түгел лә! Гөлсирин аны шулай атап һич тә мыскылларга җыенмый. Егетнең җаны изге икәнен белә ул» [2, б. 72]

Язучының төп герой тормышын гади, күп язмышларның берсе итеп бирүе, һәр кешедә яхшы һәм начар сыйфатлар булган кебек, Маратның тышкы һәм эчке дөньясының тәңгәл килмәве, ана белән бала мөнәсәбәтләренең бөтен тулылыгында сурәтләнүе чынбарлыкка якынлык тудыра, уйландыра.

«Соңгы очрашу» (1983) әсәрендә игътибар кеше психологиясенә юнәлтелә, сюжет нигезенә гадәти булмаган күренеш – кеше белән эт

арасындагы мөнәсәбәтләр салынган. Аучы Сабир үзсүзлелеге, горурлыгы аркасында тугры дусты Алаколакның бердәнбер баласын чабып үтерә. Эт моны кичерә алмый – явыз, ерткыч бүрегә әйләнә; хуҗасының сыерын, сарыкларын чәйнәп бетерә. Алаколакның явызлыгы Сабирдан кала бирәүгә дә тими, тора-бара эт аны да тынычлыкта калдыра: урман саклый башлый.

Соңгы көннәрендә Сабир − бәхетсез. Карт җан тынычлыгы таба алмый. Бәхетсезлекнең сәбәбе нәрсәдә? Язучы турыдан-туры бу сорауга җавап бирми, бәлки Сабир картның тормышы белән таныштыра килә, персонажның бүгенге халәтен ача. Карт үз гомерендә акча өчен меңләгән кошларны, җәнлекләрне харап иткән. Урман рәнҗешеме бу? (Урман – әдибә иҗатында изге урын, тынычлык, матурлык символы). Эт каргышымы? Бәхетсез Сабир карт Эт-Бүрене үтерү теләге белән яши. Улының үлемен Алаколак рәнҗеше дип кабул итә. Әсәр азагында Эт-Бүре белән очрашкач, карт үз гаебен таный, яшьлек дустыннан гафу үтенә. Язучы шулай кеше-табигать берлеген раслый.

«Алан уртасында ялгыз йорт» (1984) повестенда Әлфия белән Әнәснең күңел дөньялары, хисләрен күрсәтү эчке сөйләм, монолог кебек психологизм алымнары аша тормышка ашырыла. Эчке сөйләм уйланулар, хатирәләр, күз алдына баскан картиналарны үз эченә ала: «Бервакыт трамвайда күргән иде ул аны. Күрде дә сикереп торып урын бирде. Күзләрен мөлдерәтеп, Җаббаровка карады да ояла-ояла гына утыргычка сыенды. Шундый матур итеп оялды ул! Ситса күлмәгендәге алсу чәчәкләр йөгерешеп ике битенә кунды. Кыз онытылмавы белән, шактый озак җәфа чиктерде...» [1, б. 257] Биредә геройның хисләре сүз белән тасвирлана һәм аның физик эквиваленты – хәрәкәт, ишарә, кыяфәте, йөз үзгәреше китерелә.

Ялгызы гына урманда калганнан соң, Әнәснең уйлары монолог формасында бара, егет үз-үзенә күпләгән сораулар бирә, җаваплар таба алмый. «Әлфиядә нинди сагыш икән ул? Каян килгән моң аңарда? Нишләп ул Әнәснең юлына килеп басты?» [1, б. 247] һ.б. Монологлар геройның каршылыклы хисләрен, икеләнүен ачу чарасы булып тора. Әсәр азагында Әнәснең сөйгән кешесен югалтуы турындагы хәбәрне кабул итәсе килми, ул

ышанырга теләми. Бу хисләрнең ачык сурәтләнеше эчке сөйләмдә табыла. Нәкъ менә шушы алым язучы иҗатында психологизм тудыруның төп чарасына, аның стиль билгесенә әйләнә.

Гомумән алганда, Н. Гыйматдинованың 1970-1985 елларда иҗат иткән хикәя-повестьлары – тәҗрибә туплау үрнәге, алдагы чор иҗаты өчен җирлек булып тора. Аларда сюжетны кискен каршылыкларга кору, ачкыч-билгеләр, күренеш-детальләр, охшаш яки контраст образлар, хисләрне яшерү алымы, гадәти булмаган вакыйгалар сурәтләнү, эчке монологлар ярдәмендә тирән психологизм тудыру кебек поэтик алым һәм чаралар сынау үтә, язучының әдәбиятта үз юлын эзләве турында сөйли.

**Файдаланылган әдәбият:**

1. Гыйматдинова Н.М. Ут күбәләге: повестьлар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1990. – 270 б.
2. Гыйматдинова Н. М. Бердәнберем: Хикәяләр һәм повестьлар – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 168б.
3. Гыйматдинова Н.М. Су хикәяте: хикәяләр һәм повестьлар. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1981. 251 б.
4. Гыйматдинова Н. М. Талпыну: Повестьлар һәм хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 264 б.
5. Татар әдәбияты тарихы: Алты томда: 6 том: 60-90 еллар әдәбияты. Казан: «Раннур» нәшр., 2001.